КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 13 апрель г.Казань № 393

Татарстан Республикасында креатив индустрияләргә ярдәм итү инфраструктурасына караган Татарстан Республикасы мөлкәтен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» 2024 елның 8 августындагы 330-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясы, «Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» 2025 елның 26 апрелендәге 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы территориясендә креатив индустрияләргә ярдәм итү инфраструктурасын булдыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында креатив индустрияләргә ярдәм итү инфраструктурасына караган Татарстан Республикасы мөлкәтен кушымта нигезендә билгеләргә.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 13 апрель, 393 нче
карарына кушымта

Татарстан Республикасында креатив индустрияләргә
ярдәм итү инфраструктурасына караган Татарстан Республикасы мөлкәте
исемлеге

| Т/с | Мөлкәт исеме | Урнашу урыны | Кадастр номеры |
|---|---|---|---|
| 1. | «Казан үзәк универсаль кибете Сәүдә йорты» | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәскәү урамы, 2 нче йорт | 16:50:011907:32 |

______________________